# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында
2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**07.08.2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. « Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 30.11.2022 ел, № 4 карары нигезендә, 2023 елда тауасты Байлар авыл җирлеге бюджетына кергән 306000,0 сум күләмендә гражданнарның үзара салым акчаларын кулланырга Дәвек торак пунктындагы скважина бораулау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) һәм күрсәтелгән акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

«Дәвек торак пунктында су манарасын сатып алу һәм монтажлау (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр өчен түләү)».

2. Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң ун көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы З. С. Гәрәева

ОГРН 1021605552792
р 06-115/09
Совет
ПОДГОРНО-
БАЙЛАРСКОГО
сельского поселения
ИНН 1628002996